МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.09.2023________________ г. Казань № под-1549/23_____

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 11 мартындагы под-431/16 номерлы «Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы «Рәсәй Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законына, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законына, 2010 елның 01 июлендәге 821 номерлы «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» Рәсәй Федерациясе Президенты Указына, Татарстан Республикасының 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» Законына, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» Законына ярашлы рәвештә б о е р а м:

1. 11.03.2016 елның под-431/16 номерлы «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында» боерыгына (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 22.03.2018 ел №519/18, 24.10.2022 ел №под-1793/22, 11.05.2023 ел №под-967/23 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Кушымталарны расларга:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия составы.»;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында Нигезләмәсендә:

2.1 пункттагы беренче җөмләне алып ташларга;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Министр комиссия составына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет, министрлыкның профсоюз оешмасы, министрлыкта булдырылырга мөмкин булган ветераннарның иҗтимагый оешмасы вәкилләрен кертү турында Карар кабул итә ала»;

3.2 пунктын «атасының исеме» сүзеннән соң «(булган очракта)» сүзләре белән тулыландырырга;

3.23 пунктның «а», «б», «д» пунктчаларында «атасының исеме» сүзеннән соң «(булган очракта)» сүзләре белән тулыландырырга;

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия составы белән тулыландырырга (кушымта беркетелә).

2. Министрлыкның Мәгълүмати технологияләр һәм иминлек үсеше бүлегенә (И.Н.Сарманов) әлеге боерыкны Министрлыкның рәсми сайтының «Коррупциягә каршы тору» бүлегендәге «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе» / «Норматив документлар» өлешендә урнаштырырга.

3. Кадрлар сәясәте бүлегенә (Л.С. Әмирова) әлеге боерыкны Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән срокта Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвен тәэмин итәргә.

4. Бу боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Министр И.Г.Һадиуллин

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның «11» мартында № под-431/16 боерыгы белән расланган
(Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының
«05» ____09______ 2023 № под-1549/23 боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия составы

| № п/п | Фамилия, исем, атасы исеме | Вазифа |
|---|---|---|
| Комиссия рәисе | | |
| 1 | Поминов Андрей Иванович | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары |
| Комиссия рәисе урынбасары | | |
| 2 | Музипов Рәмис Гаптрәис улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары, Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты җитәкчесе |
| Комиссия сәркатибе | | |
| 3 | Гатауллина Гүзәл Хәйдәр кызы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Кадрлар сәясәте бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе |
| Комиссия әгъзалары | | |
| 4 | Алексеева Татьяна Георгиевна | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Гомуми белем бирү идарәсе башлыгы |
| 5 | Федоров Андрей Александрович | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Һөнәри белем бирү идарәсе башлыгы |
| 6 | Әмирова Лилия Сәлимҗан кызы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Кадрлар сәясәте бүлеге башлыгы |
| 7 | Борисова Елена Сергеевна | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Юридик бүлек башлыгы |
| 8 | Шрша Равия Бәдертдин кызы | Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең Коррупциягә каршы тикшерүләр бүлеге мөдире (килешү буенча) |
| 9 | Туфитуллов Айдар Миралим улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном белем бирү учреждениесенең Икътисади куркынычсызлык һәм салым салу кафедрасы мөдире (килешү буенча) |
| 10 | Гибатдинов Марат Мингали улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесенең фәнни эшләр буенча директор урынбасары (килешү буенча) |
| 11 | Яруллин Илдар Мәхмүт улы | Гомумроссия мәгариф хезмәткәрләре профсоюзының Татарстан республика оешмасы рәисе урынбасары (килешү буенча) |